ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮШАДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮШАДЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

12.09.2026ел № 8

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юшады авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында.

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексы, «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принңиплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль Законның 47 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге» муниңипаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге башлыгы:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Юшады авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны оештыручы составын-коллегиаль киңәшмә органын расларга:

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юшады авыл җирлеге башлыгы Ханов И. Р.

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы башлыгы урынбасары Хисамбеев Н. К.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының "ПИЗО" МКУ рәисе Р. С. Шакиров;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетыныц төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы урынбасары-баш архитектор Петров В. К.;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Советының юридик секторы мөдире Петрова А. В.

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга гавами тыңлауларны җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 26 сентябрнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Житкәче И. Р. Ханов